СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.07.2018 ел Баулы шәһәре № 161

Хезмәт (вазифа) тәртибенә таләпләрне
үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын
җайга салу комиссиясе турында
нигезләмә раслау турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы, 2008 елның 25 декабрендә кабул ителгән «Коррупциягә каршы тору турында»гы 273-ФЗ санлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы карар итте:

1. Хезмәт (вазифа) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә расларга.

2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы 2016 елның 14 июлендә кабул иткән «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазифалар биләүче затларның вазифаи тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау турында»гы 66нчы карарны гамәлдән чыгарылган дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы рәсми сайтына һәм мәгълүмат-телекоммуникацион интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе

АППАРАТ СОВЕТА
СОВЕТ АППАРАТЫ

Р.Х. Гатиятуллин

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы Советы
2018 елның 3 июлендә кабул иткән
161нче санлы карарга нигезләмә

**Хезмәт (вазифа) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге нигезләмә нигезендә, 2008 елның 25 декабрендә кабул ителгән «Коррупциягә каршы тору турында»гы 273-ФЗ санлы федераль закон ( алга таба – 273-ФЗ санлы Федераль закон), 2007 елның 2 мартында кабул ителгән «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы федераль закон, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында Кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында хезмәт (вазифа) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясен формалаштыру һәм эшчәнлеге тәртибе билгеләнә.

1.2. Комиссия Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе федераль законнарына һәм башка хокукый норматив актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм башка хокукый норматив актларына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставына, әлеге Нигезләмәгә һәм башка муниципаль хокукый норматив актларга таянып эш итә.

1.3. Комиссиянең төп бурычы – Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары) ярдәм итү:

а) муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазифалар биләүче затларның мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу турындагы чикләүләр һәм тыюларны үтәвен тәэмин итүгә, шулай ук аларның 273-ФЗ санлы Федераль закон, башка федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән бурычларны (алга таба – хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр) үтәвен тәэмин итүгә;

б) җирле үзидарә органы ведомствосындагы оешмалар (учреждениеләр) җитәкчеләренең мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәвен тәэмин итүгә;

в) җирле үзидарә органында коррупцияне булдырмау буенча чараларны тормышка ашыруга.

1.4. Комиссия түбәндәге таләпләр үтәлеше белән бәйле мәсьәләләрне карый:

муниципаль хезмәткәрләргә карата хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр;

муниципаль вазифалар биләүче затларга карата хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр;

җирле үзидарә органы ведомствосындагы оешмалар (учреждениеләр) җитәкчеләренә карата мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр.

1.5. Комиссия Татарстан Республикасының 2017 елның 19 июлендә кабул ителгән «Муниципаль вазифаларга, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазифасына дәгъва итүче гражданнар, һәм муниципаль вазифалар, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазифасын биләүче затлар биргән мәгълүматлар дөреслеген һәм тулылылыгын тикшерү турында»гы 57-ТРЗ санлы законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Президенты 2015 елның 13 октябрендә кабул иткән «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү Комиссиясе турында»гы УП-986 санлы боерык нигезендә эшләүче Татарстан Республикасын коррупциягә каршы тору эшен координацияләү Комиссиясе компетенциясендәге мәсьәләрне карамый.

## 2. Комиссия оештыру тәртибе

2.1. Комиссиясе составы Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы карары белән раслана.

Комиссия комиссия рәисеннән, аның урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазифаларын урынбасары башкара.

2.2. Комиссия составына керүчеләр:

а) Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башлыгы урынбасары (комиссия рәисе), муниципаль вазифалар биләүче затлар, җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте подразделениесе җитәкчесе яки җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтеннән коррупция һәм башка хокук бозуларны булдырмау эше өчен җаваплы вазифаи зат (комиссия сәркатибе), кадрлар хезмәтеннән, юридик (хокукый) подразделениедән, җирле үзидарә органының башка подразделениеләреннән җитәкче билгеләгән муниципаль хезмәткәрләр;

б) фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары вәкиле (вәкилләре).

2.3. Җирле үзидарә органы җитәкчесе түбәндәге кешеләрне комиссия составына кертү турында карар кабул итә ала:

а) 2017 елның 27 апрелендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы иҗтимагый палатасы турында»гы 24-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законының 24нче маддәсе нигезендә, җирле үзидарә органында оештырылган иҗтимагый совет вәкилен;

б) җирле үзидарә органында оештырылган иҗтимагый ветераннар оешмасы, җирле үзидарә органында тиешле тәртиптә эшләүче профсоюз оешмасы вәкилен.

2.4. Әлеге нигезләмәнең 2.2нче пунктның б өлешендә, 2.3нче пунктның б өлешендә күрсәтелгән затлар комиссия составына тиешле тәртиптә, җирле үзидарә органы җитәкчесе соратуы буенча, фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү оешмалары, өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары, җирле үзидарә органында оешкан иҗтимагый совет, җирле үзидарә органында оешкан иҗтимагый ветераннар оешмасы, ңирле үзидарә органында тиешле тәртиптә эшләүче профсоюз оешмасы белән килештерелеп кертелә.

2.5. Комиссиянең муниципаль хезмәт вазифаларын, муниципаль вазифалар биләмәүче әгъзалары саны комиссия әгъзалары гомуми санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.6. Комиссия составы комиссия тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеген булдырмаслык итеп төзелә.

2.7. Комиссия утырышларында киңәшмә тавыш бирү хокукы белән түбәндәгеләр катнаша:

а) аңа карата Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлеше турындагы мәсьәлә карала торган муниципаль хезмәткәрнең җитәкчесе;

б) муниципаль хезмәт вазифаларын биләүче башка муниципаль хезмәткәрләр; муниципаль вазифалар биләүче затлар; комиссия караган мәсьәләләргә аңлатма бирә алырлык белгечләр;дәүләт органнары, башка җирле үзидарә органнары вазифаи затлары; кызыксынуы булган оешмалар вәкилләре; аңа карата комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлеше турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре вәкиле, – аңа карата комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлеше турындагы мәсьәлә карала торган муниципаль хезмәткәрнең яки комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының үтенеч язуы нигезендә комиссия утырышы көненә кадәр өч календарь көненнән дә соңга калмыйча, комиссия рәисе тарафыннан һәр конкрет очракта аерым кабул ителә торган карар буенча.

2.8. Комиссия утырышы анда комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашканда тулы хокуклы була. Җирле үзидарә органнарында муниципаль вазифалар биләүче комиссия әгъзалары катнашында гына утырышлар үткәрү рөхсәт ителми.

2.9. Комиссия әгъзасының Комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне тикшергәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган кызыксынуы барлыкка килгәндә, ул утырыш башланганчыга кадәр бу хакта хәбәр итәргә тиеш. Бу очракта комиссиянең әлеге әгъзасы күрсәтелгән мәсьәләне тикшерүдә катнашмый.

**3. Комиссия тарафыннан муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлеше турындагы мәсьәләләрне карау тәртибе**

3.1. Комиссия утырышын үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль хезмәткәр тапшыра торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын һәм муниципаль хезмәткәр тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең үтәлүе буенча үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә җитәкчесе тарафыннан түбәндәгеләр хакында тикшерү материалларын тапшыру:

муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, милеге һәм милек характерендагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында норматив хокукый актта каралган белешмәләрне дөрес булмаган яки тулы булмаган күләмдә тапшыру хакында;

муниципаль хезмәткәр тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлмәве хакында;

б) муниципаль норматив хокукый актта билгеләнгән тәртиптә кергән:

җирле үзидарә органында җирле үзидарә органының норматив хокукый акты белән расланган вазифалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазифасы биләгән гражданның, дәүләт хезмәттән азат ителгән көненнән алып ике ел узганчыга кадәр, әгәр дә әлеге оешманың муниципаль идарә буенча аерым функцияләре аның вазифаи (хезмәт) бурычларына караган булса, коммерциянеке яки коммерциянеке булмаган оешмада вазифа биләүгә яисә гражданлык-хокукый шартнамә шартларында коммерциянеке яки коммерциянеке булмаган оешмада эшләр башкаруга рөхсәт бирү турындагы мөрәҗәгате;

муниципаль хезмәткәрнең нигезле сәбәпләр буенча хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милеге яки милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру мөмкинлеге булмау турындагы гаризасы;

муниципаль хезмәткәрнең, территориясендәге чит ил банкларында счетлары (кертемнәре) булган, акчалата акча чаралары һәм кыйммәтләре саклана торган һәм (яки) чит ил финанс инструментлары булган чит илдә дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан әлеге чит ил дәүләте законнары нигезендә салынган арестка, эш итүне тыюга бәйле сәбәпле, яки аның ихтыярына яки аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка шартлар булу сәбәпле, 2013елның 7 маенда кабул ителгән «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата акча чараларын һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 79-ФЗ номерлы Федераль закон

(алга таба – «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата акча чараларын һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» Федераль закон) таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмавы турында гаризасы;

муниципаль хезмәткәрнең вазифаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерәчәк яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксынуы барлыкка килүе турында гаризасы;

в) җирле үзидарә органы җитәкчесенең яисә комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының муниципаль хезмәткәр тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында яисә җирле үзидарә органында коррупцияне булдырмау чаралар башкаруга карата таләпләр үтәлешенә кагыла торган гаризасы;

г) җирле үзидарә органы җитәкчесенең 2012 елның 3 декабрендә кабул ителгән «Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килү-килмәүгә контрольлек итү хакында»гы 230-ФЗ санлы Федераль законның (алга таба – 230-ФЗ санлы Федераль закон) 3нче маддәсенең 1нче өлешендә каралган мәгълүматларны дөрсе булмаган яки тулы булмаган күләмдә тапшыруы турында дәлилли торган материаллар тапшыру;

д) 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы көрәш турында" 273-ФЗ санлы Федераль законның 12нче маддәсенең 4нче өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 статьясы нигезендә коммерциянеке яки коммерциянеке булмаган оешмадан җирле үзидарә органына килгән, җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазифасын биләгән граждан белән, әгәр дә җирле үзидарә органында вазифа биләү вакытында муниципаль идарәнең аерым функцияләре аның тарафыннан башкарыла торган вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, күрсәтелгән гражданга комиссия тарафыннан элегрәк әлеге оешма белән хезмәт һәм гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләргә керүгә ризалык бирелмәсә яки мондый гражданга аның тарафыннан коммерциянеке яки коммерциянеке булмаган оешмада вазифа биләүгә яисә аның тарафыннан гражданлык-хокукый шартнамә шартларында коммерциянеке яки коммерциянеке булмаган оешмада эшләр башкаруга рөхсәт бирү турындагы мәсьәлә комиссия тарафыннан каралмаган булса, эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яки гражданлык-хокукый шартнамә төзү турында белдерүнамә.

3.2. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турындагы хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасы бозылу очраклары буенча тикшерүләр үткәрми.

3.2.1. Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" өлешенең икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны буенча адресы, муниципаль хезмәттән азат ителгән көннән башлап соңгы ике ел дәвамында биләгән

вазифалары, коммерциянеке яки коммерциянеке булмаган оешманың исеме, урнашкан урыны, аның эшчәнлек итү характеры, гражданның аның тарафыннан муниципаль хезмәт вазифасын биләгәндә башкарылган вазифаи (хезмәт) бурычлары, коммерциянеке яки коммерциянеке булмаган оешмага карата муниципаль идарә буенча функцияләр, шартнамә төре (хезмәт яки гражданлык-хокукый), күзалланган гамәлдәге вакыты, шартнамә буенча эшләр (хезмәтләр) башкаруга (күрсәтүгә) түләү суммасы. Мөрәҗәгать тикшерелә, аның нәтиҗәсендә, 273-ФЗ санлы Федераль законның 12нче маддәсе таләпләрен исәпкә алып, мөрәҗәгатьнең асылы буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә.

3.2.2. Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы "б" өлешенең икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать үзенең муниципаль хезмәттән китүен планлаштыручы муниципаль хезмәткәр тарафыннан бирелергә мөмкин һәм комиссия тарафыннан Нигезләмә нигезендә карап тикшерелергә тиеш.

3.2.3. Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы "д" өлешендә күрсәтелгән белдерүнамә тикшерелә, муниципаль хезмәт вазифасын биләгән граждан тарафыннан 273-ФЗ санлы Федераль законның 12нче маддәсендәге таләпләрнең үтәлеше турында дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә.

3.2.4. Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы "б" өлешенең бишенче абзацында күрсәтелгән белдерүнамәне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә.

3.2.5. Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы "б" өлешенең икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне, Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы "б" өлешенең бишенче абзацында һәм "д" өлешендә күрсәтелгән белдерүнамәләрне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерләгәндә, комиссия мөрәҗәгать яки белдерүнамә тапшырган муниципаль хезмәткәр белән әңгәмә үткәрергә, аңардан язмача аңлатма алырга хокуклы. Җирле үзидарә органы җитәкчесе яки аның моның өчен вәкаләтле урынбасары дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, кызыксынуы булган оешмаларга тиешле тәртиптә сорату юлларга мөмкин. Мөрәҗәгать яки белдерүнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә юллана. Соратулар юлланган очракта, мөрәҗәгать яки белдерүнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар комиссия рәисенә Мөрәҗәгать яки белдерүнамә кергән көннән соң 45 көн эчендә тапшырыла. Әлеге срок озынайтылырга мөмкин, тик 30 көннән дә күбрәк вакытка түгел.

3.3. Комиссия рәисе, муниципаль норматив хокукый актларда каралган тәртиптә, комиссия утырышын уздыруга нигез булырлык мәгълүмат кергәннән соң, түбәндәгеләрне эшли:

а) 10 көн эчендә комиссия утырышы датасын билгели. Утырыш датасы мәгълүмат кергәннән соң 20 көннән дә соңга калмыйча билгеләнә (искәрмә – Нигезләмәнең 3.3.1 һәм 3.3.2нче пунктларынд каралган очраклар);

б) аңа карата Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлеше турында мәсьәлә тикшерелүче муниципаль хезмәткәрне, аның вәкилен,

комиссия әгъзаларын һәм комиссия утырышында катнашучы башка затларны мәгълүмат һәм аны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруны оештыра;

в) Комиссия утырышына Нигезләмәнең 2.7нче пунктындагы “б”өлешендә күрсәтелгән затларны чакыру турындагы үтенеч язуларын тикшерә, аларны канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турында һәм комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны тикшерү (тикшерүдән баш тарту) турында карарлар кабул итә.

3.3.1. Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы “б” өлешенең өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны тикшерү буенча комиссия утырышы керемнәр, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән вакыт узган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

3.3.2. Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы “д” өлешендә күрсәтелгән белдерүнамә, кагыйдә буларак, комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында тикшерелә.

3.4. Комиссия утырышы аңа карата комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлеше турында мәсьәлә тикшерелүче муниципаль хезмәткәр яки җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазифасын биләгән граждан катнашында үткәрелә. Муниципаль хезмәткәр (яки гражданин) комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләве турында Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы “б” өлеше нигезендә тапшырылган мөрәҗәгатендә, гаризасында яки белдерүнамәсендә күрсәтә.

3.4.1. Комиссия утырышлары муниципаль хезмәткәр (яки гражданин) катнашыннан башка түбәндәге очракларда үткәрелергә мөмкин:

а) Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы “б” өлеше нигезендә тапшырылган мөрәҗәгатендә, гаризасында яки белдерүнамәсендә комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләве турында күрсәтелмәсә;

б) утырышта катнашырга теләгән муниципаль хезмәткәр, аңа утырыш вакыты һәм урыны турында хәбәр ителеп тә, килмәсә.

3.5. Комиссия утырышында муниципаль хезмәткәр яки җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазифасын биләгән затның (алар ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана, әлеге утырышка кертелгән мәсьәләләрнең асылы буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар тикшерелә.

3.6. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашкан затлар комиссия эше барышында аларга мәгълүм булган мәгълүматларны таратырга хокуклы түгел.

3.7. Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы “а” өлешенең икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәр тапшырган белешмәләрнең дөрес һәм тулы булуын билгеләргә;

б) муниципаль хезмәткәр тапшырган белешмәләрнең дөрес булмавын һәм (яки) тулы булмавын билгеләргә. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.8. Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы “а” өлешенең өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәвен билгеләргә;

б) муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәмәвен билгеләргә. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлмәвенә юл куелмаска тиешлеген күрсәтергә, аңа карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.9. Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы “б” өлешенең икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданга, әгәр дә әлеге оешманың муниципаль идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерциянеке яки коммерциянеке булмаган оешмада вазифа биләүгә яки коммерциянеке яки коммерциянеке булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга рөхсәт бирү;

б) гражданга, әгәр дә әлеге оешманың муниципаль идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерциянеке яки коммерциянеке булмаган оешмада вазифаи биләүгә яки коммерциянеке яки коммерциянеке булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга рөхсәт бирмәү һәм бу рөхсәт бирмәүне нигезләү.

3.10. Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы “б” өлешенең өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәр тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милеге һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмавының сәбәбе объектив һәм җитди дип таныրга;

б) муниципаль хезмәткәр тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милеге һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмавының сәбәбе нигезле түгел диптаныրга. Бу очракта комиссия муниципаль хезмәткәргә күрсәтелгән белешмәләрне тапшыру буенча чаралар күрергә киңәш итә;

в) муниципаль хезмәткәр тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъбулмаган балаларының керемнәре, милеге һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмавының сәбәбе объектив түгел һәм күрсәтелгән белешмәләрне тапшырудан качу ысулы булып тора диптанырга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.10.1. Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы "г" өлешендә күрсәтелгән мәсьәләне тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәр 230-ФЗ санлы Федераль законның 3нче маддәсе 1нче өлеше нигезендә тапшырган мәгълүматларны дөрес һәм тулы дип танырга;

б) муниципаль хезмәткәр 230-ФЗ санлы Федераль законның 3нче маддәсе 1нче өлеше нигезендә тапшырган мәгълүматларны дөрес түгел һәм тулы түгел дип танырга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә һәм (яки) чыгымнарны контрольдә тоту нәтиҗәсендә алынган материалларны прокуратура һәм (яки) компетенциясе туры килгән дәүләт органнарына юлларга киңәш итә.

3.10.2. Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы "б" өлешенең дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) 79-ФЗ санлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә киртә тудыручы хәлләрне объектив һәм җитди дип танырга;

б) 79-ФЗ санлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә киртә тудыручы хәлләрне объекктив һәм җитди түгел дип танырга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.10.3. Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы "б" өлешенең бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәр вазифаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы юк;

б) муниципаль хезмәткәр вазифаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин. Бу очракта комиссия муниципаль хезмәткәргә, һәм (яки) җирле үзидарә җитәкчесенә мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу яки мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау чаралары күрергә киңәш итә.

в) муниципаль хезмәткәр мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләрен үтәмәгән дип танырга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.11. Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы «а», «б», «г» һәм «д» өлешләрендә күрсәтелгән мәсьәләне тикшерү нәтиҗәләре буенча, моңа нигезләр булган очракта, комиссия Нигезләмәнең 3.7-3.10, 3.10.1-3.10.3 и

3.11.1нче пунктларында каралганнардан аермалы булган карарлар кабул итә ала. Мондый карарны кабул итү нигезләре һәм сәбәпләре комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелергә тиеш.

11.1. Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы “д” өлешендә күрсәтелгән мәсьәләне тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) аның тарафыннан, әгәр дә әлеге оешманың муниципаль идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерциянеке яки коммерциянеке булмаган оешмада вазифа биләүгә яки коммерциянеке яки коммерциянеке булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкарылуга рөхсәт бирү;

б) аның тарафыннан коммерциянеке яки коммерциянеке булмаган оешмада вазифаи биләүнең яки коммерциянеке яки коммерциянеке булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкарылу (хезмәтләр күрсәтүнең) 273-ФЗ санлы Федераль законның 12нче маддәсендәге таләпләрне боза дип билгеләргә. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә күрсәтелгән шартлар турында прокуратура органнарына һәм хәбәр итүче оешмага җиткерү турында киңәш итә.

3.12. Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы “в” өлешендә күрсәтелгән мәсьәләне тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия тиешле карар кабул итә.

3.13. Комиссия карарларын үтәү өчен, җирле үзидарә органы норматив хокукый актлары, җирле үзидарә органы җитәкчесе карарлары яки йөкләмәләре проектлары әзерләнергә мөмкин. Алар, билгеләнгән тәртиптә, җирле үзидарә органы җитәкчесенә каралуга тәкъдим ителә.

3.14. Нигезләмәнең 3.1нче пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча комиссия карарлары яшерен тавыш биреп (әгәр комиссия башка төрле карар кабул итмәсә), комиссия утырышында катнашучы әгъзалары тавышларының гади күпчелеге нигезендә кабул ителә.

3.15. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларны комиссиянең утырышында катнашкан әгъзалары имзалый. Комиссия карарлары, Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы “б” өлешенең икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карардан кала, җирле үзидарә җитәкчесе рәисе өчен киңәш бирү характерына ия. Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы “б” өлешнең икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карар зарури характерга ия.

3.16. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) комиссия утырышының көне, утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының һәм башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) аңа карата комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлеше турында мәсьәлә тикшерелүче муниципаль хезмәткәрнең фамилиясен, исемен,

атасының исемен, вазифасын күрсәтеп, комиссия утырышында карала торган һәр мәсьәләнең формулировкасы;

в) муниципаль хезмәткәргә карата белдерелгән дәгъвалар, аларны нигезли торган материаллар;

г) муниципаль хезмәткәрнең һәм башка затларның белдерелгән дәгъваларның асылына карата аңлатмаларының эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм аларның чыгышларының кыскача эчтәлеге;

е) комиссия утырышын үткәрү өчен нигезне үз эченә алучы мәгълүмат чыганагы, мәгълүматның җирле үзидарә органына килү көне;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итүне нигезләү.

3.17. Комиссиянең карары белән риза булмаган әгъзасы язмача рәвештә үз фикерен бәян итәргә хокуклы, ул комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә беркетелергә һәм аның белән муниципаль хезмәткәр танышырга тиеш.

3.18. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе утырыш көненнән соң 3 көн эчендә җирле үзидарә органы җитәкчесенә, тулысынча яки аннан өземтә рәвешендә – муниципаль хезмәткәргә, шулай ук комиссия карары буенча – башка кызыксынган затларга җибәрелә.

3.19. Җирле үзидарә органы җитәкчесе комиссия утырышы беркетмәсен тикшерергә бурычлы һәм үз компетенциясе кысаларында муниципаль хезмәткәргә карата Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын күрү турында карар кабул иткәндә һәм коррупциягә каршы көрәш оештыруның башка төрле мәсьәләләре буенча андагы киңәшләрне исәпкә алырга хокуклы. Комиссия киңәшләрен тикшерү һәм кабул ителгән карар турында җирле үзидарә органы җитәкчесе язмача рәвештә аңа комиссия утырышы беркетмәсе кергән көннән соң бер ай эчендә комиссиягә хәбәр итә. Җирле үзидарә органы җитәкчесенең карары комиссиянең чираттагы утырышында игълан ителә һәм фикер алышуларсыз гына игътибарга алына.

3.20. Комиссия тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең гамәлләрендә (гамәл кылмавында) дисциплинар гаеп билгеләре ачыкланган очракта, бу хактагы мәгълүмат, дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын күрү турында мәсьәләне хәл итү өчен, җирле үзидарә органы җитәкчесенә тапшырыла.

3.21. Комиссия тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең административ хокук бозу билгеләрен яки җинаять составын үз эченә алучы гамәлләрне кылуы (гамәл кылмавы) ачыкланган очракта, комиссия рәисе күрсәтелгән гамәл кылыну (гамәл кылынмау) турындагы мәгълүматны һәм мондый очракны раслый торган документларны 3 көн эчендә, ә кирәк булганда – кичекмәстән, хокук кулланучы органнарга тапшырырга бурычлы.

3.22. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яки аннан алынган өземтә аңа карата комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм

(яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлеше турында мәсьәлә карап тикшерелгән дәүләт хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

3.22.1. Комиссия карарыннан алынган, комиссиянең сәркатибе имзасы һәм җирле үзидарә органы мөһере белән таныкланган өземтә аңа карата Нигезләмәнең 3.1нче пунктындагы "б" өлешенең икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә тикшерелгән, җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазифасын биләгән гражданга имзалатып тапшырыла яки аның тарафыннан мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча, комиссиянең тиешле утырышы үткәрелгән көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча, белдерүнамә белән заказлы хат итеп җибәрелә.

3.23. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм документаль яктан тәэмин итү, шулай ук комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, утырыш көне, вакыты һәм үткәрү урыны турында хәбәр итү, комиссия әгъзаларын комиссия утырышында фикер алышу өчен тапшырыла торган материаллар белән таныштыру Баулы муниципаль районы Советы Аппаратының кадрлар белән тәэмин итү бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 4. Комиссиянең муниципаль вазифалар биләүче затларның хезмәт тәртибенә таләпләр үтәлешенә һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе

4.1. Комиссия утырышын уздыруга түбәндәгеләр нигез була:

а) муниципаль вазифа биләүче затның хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне бозуы турында закончалык нигезендә кергән материаллар нигезендә комиссия рәисе кабул иткән карар;

б) Комиссиягә вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында кергән белдерүнамә, шулай ук дәлилләнгән бәяләмә һәм башка материаллар.

4.2. Комиссия Нигезләмәнең 4.1нче пунктындагы "б" өлешендә күрсәтелгән белдерүнамәне башлангыч тикшерә, аны тикшерү нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә.

4.2.1. Комиссия Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башлыгы кушуы буенча Нигезләмәнең 4.2нче пунктында каралган дәлилләнгән бәяләмә әзерләгәндә, Нигезләмәнең 4.1нче пункты нигезендә белдерүнамә тапшырган заттан, тиешле тәртиптә, кирәкле аңлатмалар алырга хокуклы, ә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башлыгы, тиешле тәртиптә, федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенеө башка субъектлары дәүләт власте органнарына, җирле үзидарә органнарына, кызыксынган оешмаларга соратулар юллый ала.

Белдерүнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар белдерүнамә кергән көннән соң җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә бирелә.

Соратулар юлланган очракта, мөрәҗәгать яки белдерүнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар комиссия рәисенә мөрәҗәгать яки белдерүнамә кергән көннән соң 45 көн эчендә тапшырыла. Әлеге срок озынайтылырга мөмкин, тик 30 көннән дә күбрәк вакытка түгел.

4.3 Комиссиянең Нигезләмәнең 4.1нче пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне тикшерү планлаштырылучы утырышы датасын һәм урынын комиссия рәисе билгели.

4.4. Комиссия сәркатибе комиссия утырышына куелачак мәсьәләләрне тикшерүгә әзерлекне тәэмин итә, шулай ук комиссия әгъзаларына һәм муниципаль вазифа биләүче затларга комиссия утырышының көн тәртибенә куелган мәсьәләләр турында, утырышның датасы, вакыты, урыны хакында утырыш датасына кадәр җиде эш көне алдан хәбәр итә.

4.5. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының берсенә карата хезмәт тәртибенә таләпләр үтәлеше яки мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу мәсьәләсе тикшерелгән очракта, әлеге комиссия әгъзасы Нигезләмәнең 4.9, 4.10нчы пунктларында каралган карарлар кабул иткәндә, тавыш бирү хокукына ия булмый.

4.6. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, Нигезләмәнең 4.1нче пункты нигезендә белдерүнамә тапшырган зат катнашында уза. Ул утырышта катнашырга теләве турында белдерүнамәсендә яки гаризасында күрсәтә.

4.6.1. Комиссия утырышы түбәндәге очракларда Нигезләмәнең 4.1нче пункты нигезендә белдерүнамә тапшырган зат катнашыннан башка уза ала:

а) Нигезләмәнең 4.1нче пункты нигезендә тапшырылган мәрәҗәгатендә, гаризасында яки белдерүнамәсендә комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләве турында күрсәтелмәсә;

б) белдерүнамә тапшырган зат утырышта катнашырга теләп тә, аңа утырыш вакыты һәм урыны турында хәбәр ителеп тә, килмәсә.

4.7. Комиссия утырышында, комиссия рәисе билгеләгән тәртиптә, муниципаль вазифа биләүче затның аңлатмалары тыңлана, утырышның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләргә кергән материаллар тикшерелә. Утырышта муниципаль вазифа биләүче затның үтенече буенча башка затлар да чыгыш ясарга, алар китергән материаллар тикшерелергә мөмкин.

4.8. 4.8. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашкан затлар комиссия эше барышында аларга мәгълүм булган мәгълүматларны таратырга хокуклы түгел.

4.9. Нигезләмәнең 4.1нче пунктындагы "а" өлеше нигезендә, комиссия материалларны тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) каралган очракта муниципаль вазифа биләүче зат тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрне бозу билгеләре юк дип билгеләргә;

б) каралган очракта муниципаль вазифа биләүче зат тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрне бозу билгеләре бар дип билгеләргә.

4.10. Нигезләмәнең 4.1нче пунктындагы “б” өлешендә күрсәтелгән белдерүнамәне тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) белдерүнамә тапшырган зат вазифаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы юк дип танырга;

б) белдерүнамә тапшырган зат вазифаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин дип танырга. Бу очракта комиссия белдерүнамә тапшырган затка мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу яки мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау чаралары күрергә киңәш итә.

в) белдерүнамә тапшырган зат мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән дип танырга. Комиссия рәисе яки комиссия сәркатибе кабул ителгән карарны Россия Федерациясе закончалыгында каралган юридик җаваплылык чараларын күрергә вәкаләтле җирле үзидарә органы (башка орган) вазифаи затына җиткерә.

4.11. Комиссия тарафыннан муниципаль вазифа биләүче затның административ хокук бозу билгеләрен яки җинаять составын үз эченә алучы гамәлләрне кылуы (гамәл кылмавы) ачыкланган очракта, комиссия сәркатибе, комиссия рәисе кушуы буенча, күрсәтелгән гамәл кылыну (гамәл кылынмау) турындагы мәгълүматны һәм мондый очракны раслый торган документларны 3 көн эчендә, ә кирәк булганда – кичекмәстән, хокук кулланучы органнарга тапшырырга бурычлы.

4.12. Комиссия карарлары утырыштагы комиссия әгъзалары тавышларының гади күпчелеге нигезендә кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

4.13. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аларны комиссия рәисе һәм сәркатибе имзалый.

4.13.1. Нигезләмәнең 4.1нче пунктындагы “б” өлешендә күрсәтелгән белдерүнамәдә аны тапшырган затның комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләве күрсәтелмәсә, комиссия рәисе карары буенча, Нигезләмәнең 4.1нче пунктындагы “б” өлешендә күрсәтелгән мәсьәлә буенча тавыш бирү, комиссия әгъзаларына сораштыру кәгазьләре һәм башка документлар юллау юлы белән читтән торып уздырылырга мөмкин.

Комиссия әгъзасы сораштыру кәгазен тутырганда комиссия тәкъдим иткән карарга үзенең фикерен белдерергә, аңа каршы яки аны яклап тавыш бирергә тиеш. Комиссия әгъзасы имзалаган сораштыру кәгазе аны алганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча комиссиягә юллана.

Комиссиянең читтән торып уздырылган тавыш бирү нәтиҗәсендә кабул ителгән карары Нигезләмәнең 4.14нче пункты таләпләре нигезендә беркетмә белән рәсмиләштерелә, комиссия әгъзаларына һәмкызыксынган затларга беркетмә имзаланганнан соң җиде эш көне эчендә юллана.

4.14. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) комиссия утырышының көне, утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының һәм башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) аңа карата мәсьәлә тикшерелүче муниципаль вазифа биләүче затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазифасын күрсәтеп, Комиссия утырышында карала торган һәр мәсьәләнең формулировкасы;

в) комиссия утырышын үткәрү өчен нигезне үз эченә алучы мәгълүмат чыганагы, мәгълүматның кергән көне;

г) муниципаль вазифа биләүче затның һәм башка затларның белдерелгән дәгъваларның асылына карата аңлатмаларының эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм аларның чыгышларының кыскача эчтәлеге;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итүне нигезләү.

4.15. Комиссиянең карар белән риза булмаган әгъзасы язмача рәвештә үз фикерен бәян итәргә хокуклы, ул комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә беркетелергә тиеш.

4.16. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе комиссия утырышы беркетмәсе имзаланганнан соң биш эш көне эчендә түбәндәге кешеләргә юллана: тикшерелгән мәсьәләгә катнашы булган муниципаль вазифа биләүчегә, аны билгеләүгә (сайлауга, раслауга) вәкаләтле вазифаи затка (җирле үзидарә органына).

4.17. Россия Федерациясе закончалыгы билгеләгән тәртиптә, комиссия карары белән риза булмыйча дәгъва юлланырга мөмкин.

## 5. Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең вазифаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерәчәк яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турындагы хәбәрен тикшерү тәртибе

5.1. Комиссия утырышын уздыруга Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең вазифаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерәчәк яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турындагы хәбәре (алга таба – белдерүнамә), шулай ук дәлилләнгән бәяләмә һәм башка материаллар нигез була.

5.2. Комиссия Нигезләмәнең 5.1нче пунктында күрсәтелгән белдерүнамәне башлангыч тикшерә, һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерли.

5.3. Комиссия, Нигезләмәнең 5.2нче пунктында каралган дәлилләнгән бәяләмә әзерләгәндә, Нигезләмәнең 5.1нче пункты нигезендә белдерүнамә тапшырган заттан, тиешле тәртиптә, кирәкле аңлатмалар алырга хокуклы, ә

оешма (учреждение) оештыручысы булган җирле үзидарә органы җитәкчесе, яки моның өчен махсус вәкаләтле урынбасары. тиешле тәртиптә, федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт власте органнарына, җирле үзидарә органнарына, кызыксынган оешмаларга соратулар юллый ала.

Белдерүнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар белдерүнамә кергән көннән соң җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә бирелә.

Соратулар юлланган очракта, мөрәҗәгать яки белдерүнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар комиссия рәисенә гариза яки белдерүнамә кергән көннән соң 45 көн эчендә тапшырыла. Әлеге срок озынайтылырга мөмкин, тик 30 көннән дә күбрәк вакытка түгел.

5.4. Комиссиянең Нигезләмәнең 5.1нче пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне тикшерү планлаштырылучы утырышы датасын һәм урынын комиссия рәисе билгели.

5.5. Комиссия сәркатибе комиссия утырышына куелачак мәсьәләләрне тикшерүгә әзерлекне тәэмин итә, шулай ук комиссия әгъзаларына һәм Нигезләмәнең 5.1, 5.3нче пунктларында күрсәтелгән башка затларга комиссия утырышының көн тәртибенә куелган мәсьәләләр турында, утырышның датасы, вакыты, урыны хакында утырыш датасына кадәр җиде эш көне алдан хәбәр итә.

5.6. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, Нигезләмәнең 5.1нче пункты нигезендә белдерүнамә тапшырган зат катнашында уза. Ул утырышта катнашырга теләве турында белдерүнамәсендә күрсәтә.

5.6.1. Комиссия утырышы түбәндәге очракларда Нигезләмәнең 5.1нче пункты нигезендә белдерүнамә тапшырган зат катнашыннан башка уза ала:

а) белдерүнамәдә аны тапшырган затның комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләве турында күрсәтелмәсә;

б) белдерүнамә тапшырган зат утырышта катнашырга теләп тә, аңа утырыш вакыты һәм урыны турында хәбәр ителеп тә, килмәсә.

5.7. Комиссия утырышында, комиссия рәисе билгеләгән тәртиптә, Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең аңлатмалары тыңлана, утырышның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләргә кергән материаллар тикшерелә. Утырышта Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең үтенече буенча башка затлар да чыгыш ясарга, алар китергән материаллар тикшерелергә мөмкин.

5.8. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашкан затлар комиссия эше барышында аларга мәгълүм булган мәгълүматларны таратырга хокуклы түгел.

5.9. Нигезләмәнең 5.1нче пунктында күрсәтелгән белдерүнамәне тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) белдерүнамә тапшырган зат вазифаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы юк дип танырга;

б) белдерүнамә тапшырган зат вазифаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин дип

таныра. Бу очракта комиссия белдерүнамә тапшырган затка мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу яки мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау чаралары күрергә киңәш итә.

в) белдерүнамә тапшырган зат мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән дип таныра. Бу очракта комиссия рәисе оешма (учреждения) оештыручы булган җирле үзидарә органы җитәкчесенә - оешма (учреждения) җитәкчесенә карата җаваплылык чарасы күрергә, белдерүнамә тапшырган затка мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу чараларын күрергә киңәш итә.

5.10. Комиссия тарафыннан Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең административ хокук бозу билгеләрен яки җинаять составын үз эченә алучы гамәлләрне кылуы (гамәл кылмавы) ачыкланган очракта, комиссия сәркатибе, комиссия рәисе кушуы буенча, күрсәтелгән гамәл кылыну (гамәл кылынмау) турындагы мәгълүматны һәм мондый очракны раслый торган документларны 3 көн эчендә, ә кирәк булганда – кичекмәстән, хокук куллануычы органнарга тапшырырга бурычлы.

5.11. Комиссия карарлары утырыштагы комиссия әгъзалары тавышларының гади күпчелеге нигезендә кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

5.12. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аларны комиссия рәисе һәм сәркатибе имзалый.

5.13. Нигезләмәнең 5.1нче пунктында каралган белдерүнамәдә аны тапшырган затның комиссия утырышында катнашу теләге күрсәтелмәгән очракта, комиссия рәисе карары белән, Нигезләмәнең 5.1нче пунктындагы күрсәтелгән мәсьәлә буенча тавыш бирү, комиссия әгъзаларына сораштыру кәгазьләре һәм башка документлар юллау юлы белән читтән торып уздырылырга мөмкин.

Комиссия әгъзасы сораштыру кәгазен тутырганда комиссия тәкъдим иткән карарга үзенең фикерен белдерергә, аңа каршы яки аны яклап тавыш бирергә тиеш. Комиссия әгъзасы имзалаган сораштыру кәгазе аны алганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча комиссиягә юллана.

Комиссиянең читтән торып уздырылган тавыш бирү нәтиҗәсендә кабул ителгән карары Нигезләмәнең 4.15нче пункты таләпләре нигезендә беркетмә белән рәсмиләштерелә, комиссия әгъзаларына һәмкызыксынган затларга беркетмә имзаланганнан соң җиде эш көне эчендә юллана.

5.14. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) комиссия утырышының көне, утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының һәм башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) аңа карата мәсьәлә тикшерелүче Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазифасын күрсәтеп, Комиссия утырышында карала торган һәр мәсьәләнең формулировкасы;

в) комиссия утырышын үткәрү өчен нигезне үз эченә алучы мәгълүмат чыганагы, мәгълүматның кергән көне;

г) Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең һәм башка затларның белдерелгән дәгъваларның асылына карата аңлатмаларының эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм аларның чыгышларының кыскача эчтәлеге;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итүне нигезләү.

5.15. Комиссиянең карар белән риза булмаган әгъзасы язмача рәвештә үз фикерен бәян итәргә хокуклы, ул комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә беркетелергә тиеш.

5.16. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе комиссия утырышы беркетмәсе имзаланганнан соң биш эш көне эчендә түбәндәге кешеләргә юллана: тикшерелгән мәсьәләгә катнашы булган Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосындагы оешма (учреждение) җитәкчесенә, оешма (учреждение) оештыручысы булган җирле үзидарә органына.

5.17. Россия Федерациясе законнары билгеләгән тәртиптә, комиссия карары белән риза булмыйча, дәгъва юлланырга мөмкин.